БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__30__» __04___ 2020 ел № _165_

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү тәртибен раслау турында**

«Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның __30.04.__________
__165___ номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең хезмәткәрләренә –яшь белгечләренә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр бирү тәртибе

2020 ел

1. Әлеге Тәртип оештыручысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Балтач район башкарма комитеты булган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура - спорт оешмаларында (алга таба - оешмалар) эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләр бирү тәртибен һәм шартларын билгели:

- ай саен эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә, әмма аена 1 111 сумнан да артмаган, стимуллаштыручы өстәмә түләү;

- хуҗалыкны төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган 20000 сум күләмендә акчалата түләү.

2. Оешма хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган акчалар хисабына Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан башкарыла.

3. Оешманың хезмәткәре - яшь белгече дип 30 яшькә кадәрге (30 яшьне кертеп), көндезге формада һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү программалары буенча дәүләт аккредитациясе алган югары белем бирү мәгариф оешмасын (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасы) беренче тапкыр тәмамлаган һәм һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә хезмәт килешүе буенча һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча түбәндәге вазифаларга эшкә алынган Россия Федерациясе гражданы танылa: физкультура буенча инструктор, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив физик культура буенча өлкән инструктор, тренер, тренировка процессы администраторы.

4. Стимуллаштыра торган айлык өстәмә түләү хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә эшкә урнашу датасыннан алып вазыйфасында беренче өч ел дәвамында өзлексез эшләгәндә түләнә.

Яшь белгечләргә айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар Оешма боерыгы белән раслана.

Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү түбәндәге очракларда дәвам итә:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив граждан хезмәте;

Йөклелек һәм бала табу буенча ял (отпуск), балага өч яшь тулганчы бала карау буенча ял;

Көндезге формада аспирантурада уку.

Әгәр хезмәткәр - яшь белгеч хезмәт мөнәсәбәтләрен Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив граждан

хезмәте, йөклелек һәм бала табу буенча ял, балага өч яшь тулганчы бала карау буенча ял тәмамланганнан соң, 60 көннән дә соңга калмыйча хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерә, айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү дәвам итә.

5. Хезмәткәр - яшь белгеч шундый ук вазифага башка Оешмага күчкәндә, 30 көннән дә артмаган вакытка эштән туктап тору рөхсәт ителә.

6. Хезмәткәрне – яшь белгечне штат саны кимүгә бәйле рәвештә эштән азат иткәндә яисә алга таба башка Оешмага шундый ук вазифага эшкә урнашканда, 60 көннән дә артык булмаган вакытка эштән туктап тору рөхсәт ителә.

7. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

8. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү эчке бергәлек шартларында әлеге хезмәткәр - яшь белгеч эшли торган төп вазифа буенча 1 ставкадан да артмаган күләмдә билгеләнә.

9. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә: D=PxT, биредә:

D – хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләү күләме, сум;

P – хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә ай саен эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә, әмма аена төп (база) күләменнән артмаган, стимуллаштыра торган өстәмә түләү;

T - фактта эшләнгән вакыт (ставкалар). Сәгать;

10. Хуҗалыкны төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган 20000 сум күләмендә акчалата түләү хезмәткәргә бер тапкыр бирелә.

11. Хезмәткәр оешма җитәкчесе исеменә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча хуҗалыкны төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза белән һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң эшкә урнашкан оешмада ике ел дәвамында эшләү вакытында мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Эшкә алынганнан соң ике ел вакыт үткәнчегә кадәр хезмәт килешүе туктатылган очракта, әлеге срок тәмамланганчы фактта эшләнмәгән вакытка пропорциональ рәвештә билгеләнгән күләмдә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өлешен кире кайтарырга тиеш.

12. Оешмалар ай саен, агымдагы айның 5 числосына кадәр Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

- Министрлык тарафыннан расланган форма буенча акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акча бирү турында гариза;

- Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча Оешма хезмәткәрләре - яшь белгечләре реестры.

13. Министрлык әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны алар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек вакытта карый.

Оешма әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки әлеге Тәртипнең 12 пункты таләпләренә туры килми торган документларны тапшырган очракта, Министрлык гаризаны кире кайтара һәм биш көн эчендә кире кайтаруның сәбәпләрен күрсәтеп Оешмага хәбәр итә.

Оешма гаризаны кире кайтару турында хәбәрнамә алган көннән алып, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны кабат тапшыра.

14. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга оешма чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү әлеге максатларга Министрлык тарафыннан оешмага субсидияләр бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бер типтагы форма нигезендә Министрлык һәм оешма арасында төзелә торган килешү нигезендә бирелә (алга таба - Килешү).

Килешү әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң 10 көн эчендә төзелә.

15. Министрлык ай саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган оешманың шәхси счетларына хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидия күчерә.

16. Оешма Килешүдә каралган вакыт һәм форма нигезендә Министрлыкка хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләрдән файдалану турында хисап бирә.

17. Агымдагы финанс елында оешма тарафыннан файдаланылмаган субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

18. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, Министрлыкның язма таләбе нигезендә Оешма тарафыннан субсидияләр тиешле таләп алынган көннән соң 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

19. Субсидияләр бирү шартларын, шулай ук төзелгән килешүләрнең үтәлешен контрольдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан башкарыла.

20. Оешма хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә Оешмалар тарафыннан билгеләнгән хезмәт хакын түләү вакытында акчалата түләүләр бирүне тәэмин итә.